ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МЕНЗЕЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНЗӘЛӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

27.04.2018 г.Мензелинск № 486

Минзәлә муниципаль район бюджет өлкәсендә эшләүчеләрнең хезмәтенә түләү буенча Бердәм тариф сеткасы кагылмаган бюджет өлкәсенең аерым оешмаларында эшләүчеләрнең хезмәтенә түләү шартлары турында

Бюджет өлкәсендә эшләүчеләрнең хезмәтенә түләү буенча Бердәм тариф сеткасы кагылмаган бюджет өлкәсенең аерым оешмаларында эшләүчеләрнең хезмәтенә түләүне тәртипкә салу һәм социаль гарантияләр белән тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 30.03.2018 елдагы №195 Карары нигезендә,

КАРАР ЧЫГАРАМ:

Түбәндәгеләрне билгеләргә:

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының бюджет өлкәсендә эшләүчеләрнең хемәтенә түләү буенча Бердәм тариф сеткасы кагылмаган бюджет өлкәсенең аерым оешмалары (алга таба – аерым оешмалар) җитәкчеләренең, белгечләренең һәм хезмәткәрләренең хезмәт хакы айлык вазифаи окладтан, тиешле елларны хезмәт иткән өчен вазифаи окладка ай саен өстәмә түләүдән, катлаулылык һәм киеренкелек өчен вазифаи окладка ай саен өстәмә түләүдән, ай саен акчалата кызыксындырудан. Эш нәтиҗәләре буенча премияләрдән, ел саен бирелә торган түләүле отпуск биргәндә, бер тапкыр түләнә торган түләүләрдән, матди ярдәмнән, шулай ук законнар нигезендә башка түләүләрдән тора.

Белгечләрнең һәм хезмәткәрләрнең хезмәт хакы составына шулай ук һөнәрләрне берләштергән, хезмәт күрсәтү зонасын киңәйткән һәм үзенең төп эше белән бергә вакытлыча булмаган эшләүчеләр вазифаларын башкарган өчен өстәмә түләүләр кертелә;

аерым оешмаларның җитәкчеләре, белгечләре һәм хезмәткәрләренең вазифаи окладлары 11 163 сум булган Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының бюджет өлкәсендә эшләүчеләрнең хезмәтенә түләү буенча Бердәм тариф сеткасы кагылмаган, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының бюджет өлкәсендәге аерым оешманың

структур подразделениесе җитәкчесенең сәркатибенең вазифаи окладычы күләменә кабатлы рәвештә исәпләнә;

аерым учреждениеләрдә эшләүчеләргә компенсация түләүләре һәм айлык тариф ставкалары Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы бюджетыннан финанслана торган, Татарстан Республикасы бюджет өлкәсе оешмаларында эшләүчеләрнең хезмәтенә түләү буенча Бердәм тариф сеткасы нигезендә исәпләнә.

2. Расларга:

Кушымта №1 нигезендә, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы бюджет сферасында эшләүчеләрнең хезмәтенә түләү буенча Бердәм тариф сеткасы кагылмаган, бюджет өлкәсенең аерым оешмалары җитәкчеләренең һәм белгечләренең вазифаи окладлары күләмен исәплəгәндә кулланыла торган кабатлылык коэффициентларын;

Кушымта №2 нигезендә, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы бюджет сферасында эшләүчеләрнең хезмәтенә түләү буенча Бердәм тариф сеткасы кагылмаган, бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләренең вазифаи окладлары күләмен исәпләгәндә кулланыла торган кабатлылык коэффициентын;

Кушымта №3 нигезендә, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы бюджет сферасында эшләүчеләрнең хезмәтенә түләү буенча Бердәм тариф сеткасы кагылмаган, бюджет өлкәсенең аерым оешмаларының структур подразделениеләре җитәкчеләре һәм белгечләренең вазифаи окладлары күләмен исәпләгәндә кулланыла торган кабатлылык коэффициентын;

Кушымта №4 нигезендә, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы бюджет сферасында эшләүчеләрнең хезмәтенә түләү буенча Бердәм тариф сеткасы кагылмаган, бюджет өлкәсенең аерым оешмаларының структур подразделениеләре хезмәткәрләренең вазифаи окладлары күләмен исәпләгәндә кулланыла торган кабатлылык коэффициентын;

Кушымта №5 нигезендә, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы бюджет сферасында эшләүчеләрнең хезмәтенә түләү буенча Бердәм тариф сеткасы кагылмаган, бюджет өлкәсенең аерым оешмалары эшчәнлегенә хезмәт күрсәтү белән мәшгуль эшчеләрнең хезмәтенә түләү разрядлары диапазонын.

3. Аерым оешмаларның җитәкчеләренә, белгечләренә һәм хезмәткәрләргә түбәндәгеләрне билгеләргә:

1) тиешле елларны хезмәт иткән өчен вазифаи окладка ай саен өстәмә түләүне түбәндәге күләмдә билгеләргә:

| Эш стажы түбәндәгечә булганда | Процентларда |
|---|---|
| 1 елдан 5 елга кадәр | 5 |

| | |
|---|---|
| 5 елдан 10 елга кадәр | 7 |
| 10 елдан 15 елга кадәр | 10 |
| 15 елдан артык | 15 |

2) катлаулылык һәм киеренкелек өчен вазифаи окладның 10 проценты күләмендә вазифаи окладка ай саен өстәмә түләү;

3) вазифаи окладның ике проценты күләмендә ай саен акчалата бүләкләү;

4) хезмәткә түләү фондының билгеләнгән чикләрендә эш нәтиҗәләре буенча премияләр (премия күләме эшләүченең эшчәнлек нәтиҗәләреннә чыгып билгеләнә һәм максималь күләм белән чикләнми);

5) ел саен бирелә торган түләүле отпуск биргәндә, елга вазифаи окладның 120 проценты күләмендә бер тапкыр бирелә торган түләү.

Әгәр календарь ел дәвамында җитәкчегә, белгечкә, хезмәткәргә ел саен бирелә торган түләүле лтпуск бирелмәгән икән, бер тапкыр бирелә торган түләү аның эшләгән чорына пропорциональ рәвештә декабрь ае ахырында исәпләнә һәм түләнә, ә ул эштән киткән очракта – соңгы эш көненнән соңармыйча.

Ел саен бирелә торган түләүле отпуск биргәндә бер тапкыр бирелә торган түләү җитәкче, белгеч, хезмәткәр беренче ел эшләгәндә календарь елда эшләгән вакытка пропорциональ рәвештә бирелә. Эшкә кергән көннән башлап календарь елның 31 декабренә кадәр чор эшләнгән вакыт санала;

6) хезмәткә түләү фондының билгеләнгән чикләрендә матди ярдәм.

4. Һөнәрләрне берләштергән, хезмәт күрсәтү зонасын киңәйткән һәм үзенең төп эше белән бергә вакытлыча булмаган эшләүчеләр вазифаларын башкарган өчен белгечләргә һәм хезмәткәрләргә хезмәткә түләү фондының билгеләнгән чикләрендә төп эш буенча вазифаи окладның 50 проценты күләмендә өстәмә түләү билгеләргә.

5. Аерым оешмаларның эшчеләренә түбәндәгеләрне билгеләргә:

1) хезмәткәрнең җиңел автомобилен йөртүчеләргә нормадан тыш эш көннәре өчен өстәмә түләүләрне исәпләмичә, эшнең катлаулылыгы һәм киеренкелеге өчен айлык тариф ставкасына айлык тариф ставкасының 50 проценты күләмендә;

2) эш нәтиҗәләре буенча премияләр (премия күләме эшләүченең эшчәнлек нәтиҗәләреннән чыгып билгеләнә һәм максималь күләм белән чикләнми);

3) елсаен бирелә торган түләүле отпуск биргәндә, айлык тариф ставкасының 25 проценты күләмендә премияне исәпләп, ике айлык тариф ставкасы күләмендә матди ярдәм.

Әгәр календарь ел дәвамында җитәкчегә, белгечкә, хезмәткәргә ел саен бирелә торган түләүле лтпуск бирелмәгән икән, бер тапкыр бирелә торган түләү аның эшләгән чорына пропорциональ рәвештә декабрь ае

ахырында исәпләнә һәм түләнә, ә ул эштән киткән очракта – соңгы эш көненнән соңармыйча.

Ел саен бирелә торган түләүле отпуск биргәндә бер тапкыр бирелә торган түләү эшче беренче ел эшләгәндә календарь елда эшләгән вакытка пропорциональ рәвештә бирелә. Эшкә кергән көннән башлап календарь елның 31 декабренә кадәр чор эшләнгән вакыт санала;

4) хезмәткә түләү фондының билгеләнгән чикләрендә матди ярдәм;

5) хезмәткәрнең җиңел автомобилен йөртүчеләргә класслылык өчен ай саен түбәндәге күләмдә өстәмә түләүләр:

I класслы машина йөртүчеләргә – машина йөртүче сыйфатында эшләгән вакыт өчен билгеләнгән айлык тариф ставкасының 25 проценты;

II класслы машина йөртүчеләргә - машина йөртүче сыйфатында эшләгән вакыт өчен билгеләнгән айлык тариф ставкасының 10 проценты;

6) ай саен өстәмә түләү:

- һөнәрләрне берләштергән, хезмәт күрсәтү зонасын киңәйткән һәм үзенең төп эше белән бергә вакытлыча булмаган эшләүчеләр вазифаларын башкарган өчен белгечләргә һәм хезмәткәрләргә хезмәткә түләү фондының билгеләнгән чикләрендә төп эш буенча вазифаи окладның 50 проценты күләмендә өстәмә түләү билгеләргә;

төнге вакытта эшләгән өчен (22 сәгатьтән 6 сәгатькә кадәр) – сәгатьле тариф ставкасының 35 проценты күләмендә;

бәйрәм һәм ял көннәрендә эшләгән өчен – көндезге тариф ставкасының икеләтә күләмендә;

нормаланмаган эш көне өчен - хезмәткәрнең автомобилен йөртүчеләргә – айлык тариф ставкасының 50 проценты күләмендә.

6. Федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актларда каралганча, эшләүчеләргә башка төр түләүләр башкарырга.

7. Аерым оешмаларның җитәкчеләренең, белгечләренең, хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү фондын формалаштырганда, вазифаи окладларны түләү өчен юнәлтелгән акчалар суммасыннан артыграк түләү өчен түбәндәге акчалар каралуын билгеләргә (бер елга исәпләнгән 12 вазифаи окладтан чыгып):

1) тиешле елларны хезмәт иткән өчен ай саен өстәмә түләү – вазифаи окладның җиде проценты күләмендә;

2) эшнең катлаулылыгы һәм киеренкелеге өчен вазифаи окладка ай саен өстәмә түләү – вазифаи окладның 10 проценты күләмендә;

3) эш нәтиҗәләре буенча премияләр – вазифаи окладларның бер проценты күләмендә;

4) ай саен бирелә торган акчалата бүләк – вазифаи окладның ике проценты күләмендә;

5) ел саен бирелә торган түләүле отпуск биргәндә бер тапкыр бирелә торган түләү һәм вазифаи окладның 10 проценты күләмендә матди ярдәм.

8. Аерым оешмаларның эшчеләренең хезмәтенә түләү фондын формалаштырганда, вазифаи окладларны түләү өчен юнәлтелгән акчалар суммасыннан артыграк түләү өчен түбәндәге акчалар каралуын билгеләргә (бер елга исәпләнгән):

1) эшнең катлаулылыгы һәм киеренкелеге өчен айлык тариф ставкаларына ай саен өстәмә түләү – бер айлык тариф ставкалары күләмендә;

2) машина йөртүчеләргә класслылык, нормадан тыш эш көне өчен – тугыз айлык тариф ставкалары күләмендә;

3) эш нәтиҗәләре буенча премияләр – өч айлык тариф ставкалары күләмендә;

4) ел саен бирелә торган түләүле отпуск биргәндә матди ярдәм – айлык тариф ставкаларының 25 проценты күләмендәге премияне исәпкә алып, ике айлык тариф ставкалары күләмендә.

9. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

аерым оешмаларның җитәкчеләре, белгечләре һәм хезмәткәрләренең вазифаи окладлары күләмнәре, шулай ук аерым оешмаларда эшләүчеләргә айлык һәм башка түләүләр күләме арту ягына таба тулы бер сумга кадәр түгәрәкләнергә тиеш;

аерым оешмаларның җитәкчеләре һәм белгечләренең вазифаи окладларын күтәрү Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль район муниципаль хезмәткәрләренең вазифаи окладларын күтәрү өчен каралган күләмдә һәм срокларда башкарыла;

аерым оешмалар хезмәткәрләренең вазифаи окладларын күтәрү Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районында эшләүчеләрнең шундый ук категориядәге вазифаи окладларны күтәрү өчен каралган күләмдә һәм срокларда башкарыла.

Гамәлдәге карар кабул ителү белән аерым оешмаларда эшләүчеләрнең хезмәткә түләүнең башка шартлары кулланылмый.

10. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының финанс-бюджет һәм җир-милек палатасына гамәлдәге карарны тормышка ашыру белән бәйле чыгымнарны финанслауны билгеләнгән тәртиптә тәэмин итәргә.

11. Аерым оешмаларның җитәкчеләренә:

хезмәткәрләрнең вазифалары атамаларын гамәлдәге карарны кушымта №1 белән тәңгәл китерергә;

аерым оешмаларда эшләүчеләргә өстәмәләр һәм башка түләүләр билгеләү турында моңа кадәр чыгарылган актларны гамәлдәге карар белән тәңгәл китерергә.

12. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль район Башкарма комитеты Җитәкчесенең түбәндәге карарлары көчен югалткан дип танырга:

Минзәлә муниципаль район Башкарма комитеты Җитәкчесенең 15.06.2006 елдагы “Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы буенча бюджет өлкәсендәге аерым оешмаларда эшләүчеләрнең хезмәтенә түләү буенча Бердәм тариф сеткасы кагылмый торган бюджет өлкәсенең аерым оешмаларында эшләүчеләрнең хезмәтенә түләү шартлары турында”гы №191;

Минзәлә муниципаль район Башкарма комитеты Җитәкчесенең 17.04.2008 елдагы “Аерым оешмаларда эшләүчеләрнең хезмәтенә түләү буенча Бердәм тариф сеткасы кагылмый торган бюджет өлкәсенең аерым оешмаларында эшләүчеләрнең хезмәтенә түләү шартлары турында”гы №204;

27.10.2008 елдагы “Минзәлә муниципаль районы буенча бюджет өлкәсендәге аерым оешмаларда эшләүчеләрнең хезмәтенә түләү буенча Бердәм тариф сеткасы кагылмый торган бюджет өлкәсенең аерым оешмаларында эшләүчеләрнең вазифаи окладлары күләмен күтәрү турында” №693;

17.10.2012 елдагы “Минзәлә муниципаль районы буенча бюджет өлкәсендәге аерым оешмаларда эшләүчеләрнең хезмәтенә түләү буенча Бердәм тариф сеткасы кагылмый торган бюджет өлкәсенең аерым оешмаларында эшләүчеләрнең вазифаи окладларын 2012 елның 1 октябреннән күтәрү турында”гы №1181;

16.10.2013 елдагы “Минзәлә муниципаль районы буенча бюджет өлкәсендәге аерым оешмаларда эшләүчеләрнең хезмәтенә түләү буенча Бердәм тариф сеткасы кагылмый торган бюджет өлкәсенең аерым оешмаларында эшләүчеләрнең вазифаи окладларын 2013 елның 1 октябреннән күтәрү турында”гы №1027;

24.08.2017 елдагы “Минзәлә муниципаль районы буенча бюджет өлкәсендәге аерым оешмаларда эшләүчеләрнең хезмәтенә түләү буенча Бердәм тариф сеткасы кагылмый торган бюджет өлкәсенең аерым оешмаларында эшләүчеләрнең вазифаи окладлары күләмен күтәрү турында”гы №805;

13.Гамәлдәге карар рәсми төстә басылганнан соң 10 көн узгач көченә керә һәм 2018 елның 1 апреленнән барлыкка килгән хокукый мөнәсәбәтләргә кагыла.

Минзәлә муниципаль район
Башкарма комитеты
Җитәкчесе вазифаларын башкаручы В.Р.Гыйләҗетдинов.

Татарстан Республикасы
Минзәлә муниципаль район
Башкарма комитеты Җитәкчесе Карарына
Кушымта №1
Дата 27.09.18 № 486

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы бюджет сферасында эшләүчеләрнең хезмәтенә түләү буенча Бердәм тариф сеткасы кагылмаган, бюджет өлкәсенең аерым оешмалары җитәкчеләренең һәм белгечләренең вазифаи окладлары күләмен исәпләгәндә кулланыла торган кабатлылык коэффициентлары

| Вазифа атамасы | Коэффициент |
|---|---|
| 1.Бюджет өлкәсе оешмалары | |
| Оешма җитәкчесе | 2,25 |
| Оешма җитәкчесе урынбасары | 2,0 |
| Оешма составындагы идарә начальнигы | 1,8 |
| Бүлек начальнигы, җитәкче ярдәмчесе | 1,65 |
| Бүлек начальнигы урынбасары | 1,55 |
| Баш белгеч | 1,4 |
| Әйдәп баручы белгеч | 1,17 |
| I категорияле белгеч | 1,12 |
| II категорияле белгеч | 1,1 |
| Белгеч | 1,08 |

Искәрмә:

Бер үк вакытта структур подразделение җитәкчесе булган җитәкче урынбасарының вазифаи окладлары күләме тиешле җитәкче урынбасары вазифасы буенча билгеләнә.

Кабул итү бүлмәсе мөдирләренең (начальникларының), беренче бүлекнең, гомуми бүлекнең, канцеляриянең, хуҗалык бүлегенең һәм башка шундый подразделениеләрнең вазифаи окладлары тиешле оешманың баш, әйдәп баручы һәм башка белгечләренең вазифаи окладлары дәрәҗәсендә билгеләнә.

Татарстан Республикасы
Минзәлә муниципаль район
Башкарма комитеты Җитәкчесе Карарына
Кушымта №2
Дата 27.04. № 480

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы бюджет сферасында эшләүчеләрнең хезмәтенә түләү буенча Бердәм тариф сеткасы кагылмаган, бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләренең вазифаи окладлары күләмен исәпләгәндә кулланыла торган кабатлылык коэффициентлары

| Вазифа атамалары | Коэффициентлар |
|---|---|
| Архив мөдире, өлкән инспектор, машина-язу, копироваль-күбәйтү бюросы мөдирләре, инспектор, статист, хуҗалык, склад мөдирләре; кассир, комендант, эш башкаручы, архивариус, стенографист, сәркатип-стенографист, машинист, экспедитор, секретарь-машинист, җитәкче сәркатибе | 1,0 |

Татарстан Республикасы
Минзәлә муниципаль район
Башкарма комитеты Җитәкчесе Карарына
Кушымта №3
Дата 27.04.18 № 486

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы бюджет сферасында эшләүчеләрнең хезмәтенә түләү буенча Бердәм тариф сеткасы кагылмаган, бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләре структур подразделениеләренең җитәкчеләре һәм белгечләренең вазифаи окладлары күләмен исәпләгәндә кулланыла торган кабатлылык коэффициентлары

| Вазифа атамалары | Коэффициент | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | I төркем | II төркем | III төркем | IV төркем | Vтөркем |
| Мөстәкыйль идарә (бүлек) җитәкчесе | 1,55 | 1,55 | 1,36 | 1,34 | 1,34 |
| Мөстәкыйль идарә (бүлек) җитәкчесе урынбасары | 1,34 | 1,34 | 1,32 | 1,30 | 1,30 |
| Бүлек начальнигы | 1,30 | 1,30 | 1,27 | 1,25 | 1,25 |
| Бүлек начальнигы урынбасары | 1,23 | 1,23 | 1.21 | 1,19 | 1,17 |
| Баш белгеч | 1,17 | 1,17 | 1,15 | 1,12 | 1,10 |
| Әйдәп баручы белгеч | 1,10 | 1,10 | 1,09 | 1,07 | 1,05 |
| I категорияле белгеч | 1,03 | 1,03 | 1,02 | 1,01 | 1,00 |
| II категорияле белгеч | 1,02 | 1,02 | 1,01 | 1,00 | 1,00 |
| Белгеч | 1,00 | 1,00 | 1,00 | 1,00 | 1,00 |

Искәрмә:

I төркем – Казан шәһәре муниципаль берәмлеге;

II төркем – Яр Чаллы шәһәр муниципаль берәмлеге;

III төркем – Әлмәт, Яшел Үзән, Түбән Кама муниципаль районнары;

IV төркем – Азнакай, Баулы, Бөгелмә, Буа, Алабуга, Зәй, Лениногорск, Нурлат, Чистай муниципаль районнары, Әлмәт, Яшел Үзән, Түбән Кама шәһәрләре, шулай ук Казан шәһәре районнары;

V төркем – Азнакай, Баулы, Бөгелмә, Буа, Алабуга, Зәй, Лениногорск, Нурлат, Чистай шәһәрләре һәм I-IV төркемгә кертелмәгән Татарстан Республикасының башка муниципаль берәмлекләре.

Татарстан Республикасы
Минзәлә муниципаль район
Башкарма комитеты Җитәкчесе Карарына
Кушымта №4
Дата 27.04.18 № 486

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы бюджет сферасында эшләүчеләрнең хезмәтенә түләү буенча Бердәм тариф сеткасы кагылмаган, бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләре структур подразделениеләре хезмәткәрләренең вазифаи окладлары күләмен исәпләгәндә кулланыла торган
кабатлылык коэффициентлары

| Вазифаның атамасы | Коэффициент |
|---|---|
| Архив мөдире, өлкән инспектор, машина-язу бюросы мөдире, копироваль-күбәйтү бюросы мөдире, инспектор, статист, хуҗалык, склад мөдирләре, кассир, комендант, эш башкаручы, архивариус, стенографист, сәркатип-стенографист, машинист, экспедитор, сәркатип-машинист, җитәкче секретаре | 1,0 |

Татарстан Республикасы
Минзәлә муниципаль район
Башкарма комитеты Җитәкчесе Карарына
Кушымта №5
Дата 27.04. № 486

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы бюджет сферасында эшләүчеләрнең хезмәтенә түләү буенча Бердәм тариф сеткасы кагылмаган, бюджет өлкәсенең аерым оешмалары эшчәнлегенә хезмәт күрсәтүдә мәшгуль эшчеләрнең хезмәтенә түләү разряды диапазоны

| Вазифаның атамасы | Коэффициент |
|---|---|
| Гардеробчы, ишегалды себерүче, курьер | 1 |
| Сторож (вахтер), производство һәм хезмәт урыннарын җыештыручы, лифтер, кладовщик, йөк ташучы | 1- 2 |
| Электрон-исәпләү һәм исәпләү машиналары операторы, биналарга комплекслы хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау буенча эшче | 2- 4 |
| Копироваль һәм күбәйтү машиналары операторы | 2-3 |
| Җиңел автомобиль йөртүче | 4-5 |

Искәрмә:
Производство һәм хезмәт урыннарын җыештыручыларга икенче разряд тариф ставкасы производство биналарын җыештыру, шул исәптән, производство калдыкларын, санузелларны һәм җәмәгать туалетларын җыештыру буенча эшләр башкарганда билгеләнә.
Машина йөртүчеләргә бишенче разряд тариф ставкасы ике-өч тип җиңел автомобильдә эшләгәндә, шулай ук автомобильләргә техник хезмәт күрсәтү махсус хезмәте булмаган очракта, автомобильгә ремонт һәм техник хезмәт күрсәткән очракта билгеләнә.